**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**9 октябрь, 2021ел** **№ 110**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф. Шәйдуллинның вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 37 статьясындагы 10 өлешенең 2 пункты, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 статьясындагы 6 өлеше, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Уставының 54 статьясындагы 1 өлешенең 2 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Шәйдуллин Дамир Фәритовичның Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасыннан үз теләге белән шәхси гаризасы нигезендә отставкасын кабул итәргә.
2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе Шәйдуллин Дамир Фәритовичның вәкаләтләре 2021 елның 9 октябрендә вакытыннан алда туктатылган дип санарга.
3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Совет рәисе,
муниципаль район Башлыгы Р.Г. Кәлимуллин